# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2022 елда Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле
авылында гражданнардан
үзара салым кертү турында

**12.11.2021 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45- ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлегендә халык җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2022 елда 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 200 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Үчәлле авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга җибәрергә:

-Үчәлле авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары (тракторчы белән техниканы арендалау, килешү буенча хезмәт өчен түләү, сыешлыкны арендалау);

-Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бәйрәм чараларын үткәрү, «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәмнәренә бүләк һәм сувенир продукция сатып алу);

- Үчәлле авылында урам утларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, урам утларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

-Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (территорияләрне яшелләндерү буенча чаралар: агачлар, чәчәкләр, куаклар сатып алу һәм утырту; территорияне корыган агачлардан һәм куаклардан чистарту, территорияне механикалаштырып чабу буенча хезмәтләр өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары һәм тример өчен запас частьләр сатып алу, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмаларның хезмәтләре, балалар өчен уен, спорт мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, территорияне санитар чистарту буенча хезмәтләр күрсәтү: санкцияләнмәгән чүплекне рекультивацияләү).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Үчәлле авыл җирлеге мәгълүмати стендында (Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында

(http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина